Татарстан Республикасы Хисап палатасы

2014 елда Татарстан Республикасы Хисап палатасы эше турында
ХИСАП

Казан – 2015 ел

Эчтәлек

Эшчәнлекнең төп күрсәткечләре 3

Экспертиза-аналитика эшчәнлеге 5

Тикшерү-ревизия эшчәнлеге 12

Россия Федерациясе Хисап палатасы, Россия Федерациясе субъектларының тикшерү-хисап органнары белән үзара хезмәттәшлек итү 35

Муниципаль берәмлекләрнең тикшерү-хисап органнары белән үзара хезмәттәшлек итү 387

Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары һәм хокук саклау органнары белән үзара хезмәттәшлек итү 41

Эшчәнлектәге хәбәрдарлык 44

2014 елда Татарстан Республикасы Хисап палатасы эше турында Хисап

Татарстан Республикасы Хисап палатасы (алга таба – Хисап палатасы) эше турында хисап «Татарстан Республикасы Хисап палатасы турындагы» Законның 33 маддәсе нигезендә әзерләнде.

Хисапта закон тарафыннан билгеләнгән максат һәм вәкаләтләрне башкару буенча Хисап палатасының 2014 елдагы эшчәнлеге нәтиҗәләре тәкъдим ителде.

Эшчәнлекнең төп күрсәткечләре

2014 елда Хисап палатасы тарафыннан Татарстан Республикасы бюджеты, Мәҗбүри медицина иминиятләштерүенең территориаль фонды бюджетын формалаштыру һәм үтәлешен тикшерү буенча, дәүләт милке белән идарә итү һәм файдалану өлкәсендә 162 тикшерү-ревизия һәм эксперизa-аналитик чара үткәрелде.

Үткәрелгән тикшерү чаралары нәтиҗәләре буенча гомумән алганда **2 349 977,6 мең сум** күләмендә бозулар **ачыкланды**, барлыгы **2 349 977,6 мең сумлык** акча барлык дәрәҗә бюджетларга **кире кайтарылды** һәм ачыкланган бозулар буенча **чаралар күрелде** (ачыкланган бозуларга карата 91,5%).

Ачыкланган бозулар турында мәгълүмат һәм барлык тикшерү чаралары материаллары Татарстан Республикасы Прокуратурасына юлланды.

Татарстан Республикасы Хисап палатасы һәм прокуратура органнары күрсәтмәсе буенча **180 вазыйфаи зат дисциплинар җаваплылыкка тартылды**, **4 кеше эш урынынан азат ителде**. **3 юридик, 37вазыйфаи зат** штраф формасында **административ җаваплылыкка тартылды**. **2 җинаять эше** кузгатылды.

2014 елда Татарстан Республикасы Хисап палатасы эше турында Хисап

Хисап палатасы эшенең төп күрсәткечләре таблицада бирелде.

Эш күрсәткече	2010 ел	2011 ел	2012 ел	2013 ел	2014 ел
I. Тикшерү-ревизия эшчәнлеге					
Үткәрелгән тикшерү-ревизия чаралары саны	51	50	53	53	54
Тикшерү-ревизия чараларын үткәргәндә тартылган объектлар саны (берәмлек)	470	481	483	487	491
Ачыкланган бозулар күләме (мең сумнарда)	2 984 585,9	3 035 829,8	3 043 991,9	2 615 511,7	2 349 977,6
II. Экспертиза-аналитика эшчәнлеге					
Үткәрелгән экспертиза-аналитика чараларның гомуми күләме	104	112	108	115	108
Әзерләнгән эксперт нәтиҗәләре	33	47	43	68	57
Әзерләнгән методик документлар	3	2	4	8	3
III. Тикшерү чараларының нәтиҗәләрен тормышка ашыру					
Чара күрү өчен күрсәтмәләр җибәрелгән	54	59	56	42	36
Бюджетка акчалар кире торгызылган һәм чара күрелгән (мең сумнарда)	1 750 696,8	1 922 464,6	2 530 004,3	2 303 355,3	2 150 982,7
Тикшерү чаралары нәтиҗәләре буенча прокуратура органнарына һәм хокук саклау органнарына җибәрелгән материаллар саны (берәмлек)	57	55	58	61	54
Хисап палатасы тикшерүе материаллары буенча административ җаваплылыкка тарту турында суд һәм башка вәкаләтле органнар кабул иткән карарлар саны	71	35	33	34	40
Татарстан Республикасы Хисап палатасы материаллары буенча ачылган җинаять эшләре саны	1	3	4	9	2

Экспертиза-аналитика эшчәнлеге

2014 елда Татарстан Республикасы бюджетын һәм Татарстан Республикасы Мәҗбүри медицина иминиятләштерүенең территориаль фонды бюджетын үтәүне беренчел, агымдагы һәм соңгы тикшерүне тормышка ашырганда 108 экспертиза-аналитика чарасы үткәрелде, аларның нәтиҗәләре Хисап палатасы бәяләмәсендә чагылыш тапты.

Беренчел тикшерү кысаларында хисап елында Татарстан Республикасының 28 закон проектына экспертиза, шулай ук 4 **дәүләт программасы** проектына һәм Татарстан Республикасы дәүләт программаларына кертелә торган үзгәрешләрнең 3 проектына экспертиза үткәрелде.

«2014-2020 елларга Татарстан Республикасы мәгариф һәм фәнне үстерү» дәүләт программасы проектына экспертиза нәтиҗәләре буенча түбәндәгеләр ачыкланды:

- дәүләт программасы проектында каралган финанслау күләменең һәм «2014 елга һәм 2015 һәм 2016 еллар план периодына Татарстан Республикасы бюджеты турында» Татарстан Республикасы Законында расланган күрсәткечләрнең туры килмәве;

- Дәүләт программаларын эшләү һәм тормышка ашыру тәртибендә каралган аерым таләпләрнең сакланмавы: бәяләү индикаторларының сан күрсәткечләре һәм программа чаралары киселешендә финанслау күләмен җентекләп бирүнең булмавы.

Шулай ук Бәяләмәдә дәүләт программасы проектының паспортында һәм аерым бүлекләрендә күрсәткечләрнең эчке ярашуы булмавы билгеләп үтелә.

«2015-2020 елларга Татарстан Республикасының коррупциягә каршы сәясәтен тормышка ашыру» дәүләт прграммасы проектына экспертиза нәтиҗәләре буенча:

- Программаны финанслауның барлык чыганакларын истә тотып акчалар күләмен;

- мәгънәви тәңгәллек фактлары булу сәбәпле программа чаралары исемлеген;

- эчке бердәмлек булмауны юкка чыгару предметы буенча Программаны тормышка ашыру нәтиҗәләрен бәяләүнең аерым индикаторларын тәгаенләргә тәкъдим ителде.

«2015-2020 елларга Татарстан Республикасының химик һәм биологик куркынычсызлыгы системасы» дәүләт программасы проектына экспертиза нәтиҗәләре буенча бәяләмәдә федераль бюджетны раслаганнан соң, Татарстан Республикасы өчен каралган бюджет акчалары күләмен исәпкә алып, үз вакытында дәүләт программасын актуальләштерү кирәклеге билгеләп үтелә.

«2014-2020 елларга Татарстан Республикасында туризм һәм кунакчыллык эшчәнлеген үстерү» дәүләт программасы проектына экспертиза нәтиҗәләре буенча проектта программа чараларын тормышка ашыру белән бәйле төп куркынычлыклар турында мәгълүмат булмавына, шулай ук көтелгән нәтиҗәләрне бәяләүнең индикаторлары тиешле дәрәҗәдә эшләп бетерелмәвенә басым ясала.

«2014-2020 елларга Татарстан Республикасы дәүләт телләрен һәм Татарстан Республикасында башка телләрне саклау, өйрәнү һәм үстерү» дәүләт программасына кертелә торган үзгәрешләр проектына экспертиза нәтиҗәләре буенча Бәяләмәдә түбәндәгеләр билгеләп үтелә:

- финанслауның планлаштырылган күләмнәренең закон белән расланган күрсәткечкә туры килмәве;

- программа чаралары киселешендә финанслау күләмнәрен тулысынча детальләштерү.

«2014-2020 елларга Татарстан Республикасында физик тәрбия, спорт, туризмны үстерү һәм яшьләр сәясәтен тормышка ашыруның нәтиҗәлелеген үстерү» дәүләт программасына кертелә торган үзгәрешләр проектына экспертиза нәтиҗәләре буенча Бәяләмәдә программа чаралары киселешендә финанслау күләмнәрен тулысынча детальләштерү, чараларны финанслау күләмнәренең нәтиҗәдәге суммар күрсәткечләргә туры килмәве, шулай ук кайбер чараларның дәүләт программасы составына кертүгә өстәмә нигезләмә кирәклеге билгеләп үтелә.

«2014-2020 елларга Татарстан Республикасында транспорт системасын үстерү» дәүләт программасына кертелә торган үзгәрешләр проектына экспертиза нәтиҗәләре буенча «Россия транспорт системасын

үстерү (2010-2020 еллар)» федераль максатчан программасы күрсәткечләреннән чыгып, аерым чаралар буенча федераль бюджет чаралары хисабына планлаштырыла торган бюджет ассигнованиеләре күләмен тәгаенләргә тәкъдим ителде.

«2015 елга һәм 2016 һәм 2017 еллар планлы вакытына Татарстан Республикасы бюджеты турында» закон проектына бәяләмәдә 2015 елга һәм 2016 һәм 2017 еллар планлы вакытына республика бюджетын төзегәндә нигез итеп алынган төп макроикътисадый күрсәткечләр фаразы республика икътисадының барлыкка килгән үсеш тенденцияләрен һәм федераль дәрәҗәдә кабул ителгән икътисадый үсеш параметрларын исәпкә алып формалаштырылганлыгы билгеләнә.

Экспертиза нәтиҗәләре буенча чираттагы финанс елына һәм планлы вакытка керемнәр һәм чыгымнар буенча Татарстан Республикасы бюджетының тәкъдим ителгән төп характеристикалары расланды. Республика бюджеты дефицитының күләме һәм аның финанслау чыганаклары, дәүләт эчке бурычының югары чиге Россия Федерациясе Бюджет кодексы билгеләгән таләпләргә туры килә.

Бәяләмәдә Татарстан Республикасының дәүләт программаларының расланган исемлегенә керә торган «2013-2023 елларга Татарстан Республикасында газ-мотор ягулыгы базарын үстерү» һәм «2015-2020 елларга Татарстан Республикасында химик һәм биологик куркынычсызлык системасы» дәүләт программаларын тормышка ашыруга Закон проектында акчалар каралмавы билгеләп үтелә.

Закон проектының икенче укылышына «2015-2020 елларга Татарстан Республикасында химик һәм биологик куркынычсызлык системасы» дәүләт программасын тормышка ашыруга бюджет акчалары республика бюджетының чыгымнарына кертелгән.

«2015 елга һәм 2016 һәм 2017 еллар планлы вакытына Татарстан Республикасы Мәҗбүри медицина иминиятләштерүе территориаль фонды бюджеты турында» закон проектына экспертиза үткәрү нәтиҗәләре буенча Мәҗбүри медицина иминиятләштерүе территориаль фонды бюджетының чираттагы финанс елына һәм планлы вакытка керемнәр һәм чыгымнар буенча тәкъдим ителгән төп характеристикалары нигезләнүе расланды. Мәҗбүри медицина иминиятләштерүе территориаль фонды 2015

елга бюджет проекты балансланган – аның дефицитын финанслау чыганакларыннан табыш һәм кертемнәр күләме каралган чыгымнар күләменә туры килә.

«2015 елга һәм 2016 һәм 2017 еллар планлы вакытына Татарстан Республикасы бюджеты турында» законга үзгәрешләр кертү турында бәяләмәләрдә (үзгәрешләр дүрт тапкыр кертелде) федераль бюджеттан, Россия Федерациясе Пенсия фонды һәм «Торак-коммуналь хуҗалыгын реформалаштыруга ярдәм фонды» Дәүләт кооперациясе бюджетыннан кире кайтарылмый торган кертемнәр күләме үзгәрү, салым һәм салым булмаган керемнәрнең аерым төрләре буенча фаразланган күрсәткечләрне тәгаенләү белән бәйле бюджет күрсәткечләренә кертелгән үзгәрешләрнең нигезле булуы билгеләп үтелде. Чыгым өлешенә кертелгән үзгәрешләр республика бюджетына максатчан кертемнәр исәбенә тормышка ашырыла торган чыгымнарны беркетү, аерым юнәлешләр буенча һәм бюджет чараларын төп бүлүчеләр арасында бюджет ассигнованиеләрен яңадан бүлү, федераль максатчан программаларын өстәмә финанслау буенча шартларны саклауның зарурлыгы белән бәйле.

Чыгымнарның аерым юнәлешләре буенча детальләү юклыгы турында Хисап палатасының бер бәяләмәсендә бирелгән күрсәтмә, ул классификация таләпләренә туры килми, Закон проектының икенче укылышына төзәтмәләр белән исәпкә алынган.

«2015 елга һәм 2016 һәм 2017 еллар планлы вакытына Татарстан Республикасы Мәҗбүри медицина иминиятләштерүе территориаль фонды бюджеты турында» законга үзгәрешләр кертү турындагы бәяләмәләрдә (үзгәрешләр өч тапкыр кертелде) бюджет күрсәткечләрен дөресләү салым һәм салым булмаган керемнәрнең аерым төрләре буенча кертемнәрнең фаразланган күрсәткечләрен, Татарстан Республикасы һәм Мәҗбүри медицина иминиятләштерүе территориаль фонды бюджетыннан кире кайтарылмый торган кертемнәр күләмен тәгаенлау белән бәйләнгәнлеге күрсәтелә. Чыгым өлешенә кертелә торган үзгәрешләр белән республика Мәҗбүри медицина иминиятләштерүе территориаль фонды бюджетына максатчан кертемнәр исәбенә тормышка ашырыла торган чыгымнар күләме аныкланды, аерым максатчан маддәләр һәм чыгым төрләре буенча бюджет ассигнованиеләре яңадан бүленде.

Татарстан Республикасы **«2013 ел өчен Татарстан Республикасы бюджеты үтәлеше турында»** һәм **«2013 ел өчен Татарстан Республикасы Мәҗбүри медицина иминиятләштерүе территориаль фонды бюджеты үтәлеше турында»** законнар проектларына экспертиза нәтиҗәләре буенча закон проекты күрсәткечләренең Татарстан Республикасы Хисап палатасы үткәргән тышкы тикшерүне узган Татарстан Республикасы бюджеты үтәлеше турында һәм Мәҗбүри медицина иминиятләштерүе территориаль фонды бюджеты үтәлеше турында Хисапларның күрсәткечләренә туры килгәнлеге расланды.

«2015 елга Татарстан Республикасында муниципаль мәктәпкәчә белем бирү оешмаларында һәркем ирешерлек һәм бушлай мәктәпкәчә белем алуга булган хокукларны тормышка ашыруның дәүләт гарантияләрен финанс белән тәэмин итү нормативларын раслау турында» һәм «2015 елга Татарстан Республикасының гомуми белем һәм һөнәри белем бирү оешмаларында һәркем ирешерлек һәм бушлай мәктәпкәчә, гомуми башлангыч, гомуми төп, гомуми урта белем алу, шулай ук өстәмә белем алуга хокукларының дәүләт гарантияләрен финанс белән тәэмин итү нормативларын раслау турында» законнар проектларына экспертизалар нәтиҗәләре буенча 2015 елга мәгариф өлкәсендә җирле бюджетларга субвенцияләр күләмнәре исәбеннән кулланыла торган нормативлар күләмнәре артуның нигезләнүе раслана.

«Татарстан Республикасында гражданнарга социаль хезмәт күрсәтү өлкәсендә аерым мәсьәләләрне көйләү турында» закон проектына экспертиза нәтиҗәләре буенча аны тормышка ашыру максатында 2015 елга Татарстан Республикасы Хезмәт, мәшгульлек һәм социаль яклау министрлыгы аппаратын тотуга бюджет акчалары күләменә төзәтмә кертергә тәкъдим ителде. Татарстан Республикасының «2015 елга һәм 2016 һәм 2017 еллар планлы вакытына Татарстан Республикасы бюджеты турында» закон проектын икенче укылышта караган вакытта әлеге тәкъдим исәпкә алынды.

Татарстан Республикасының «Оешмалар милкенә салым турында» Законына үзгәрешләр кертү турында», «Татарстан Республикасының Бюджет кодексының аерым положениеләре эшчәнлеген туктату турында», «Татарстан Республикасының «Татарстан Республикасында инвестиция эшчәнлеге турында» Законының 12 маддәсенә үзгәрешләр кертү»,

«Татарстан Республикасының «2014 елга Татарстан Республикасының гомуми белем һәм һөнәри белем бирү оешмаларында һәркем ирешерлек һәм бушлай мәктәпкәчә, гомуми башлангыч, гомуми төп, гомуми урта белем алу, шулай ук өстәмә белем алуга хокукларының дәүләт гарантияләрен финанс белән тәэмин итү нормативларын раслау турында» Законына үзгәрешләр кертү турында», «Аерым категория салым түләүчеләр өчен оешма табышына салым буенча салым ставкасын билгеләү турында», «Татарстан Республикасының «Транспорт салымы турында» Законының 6 нчы маддәсенә үзгәрешләр кертү турында» **законнары проектларына финанс-икътисадый экспертиза** нәтиҗәләре буенча әлеге закон проектларын кабул итү Татарстан Республикасы чыгым йөкләмәләренең үсүенә китермәс дип расланды.

Оператив тикшерү кысаларында һәр кварталда керемнәр килү күрсәткечләре һәм **Татарстан Республикасы бюджеты** һәм **Мәҗбүри медицина иминиятләштерүе территориаль фонды бюджеты**ның чыгымнарына законда расланган күрсәткеч белән чагыштырмада бюджетлар дефицитын каплауга тотыла торган чараларның күләмнәре һәм төзелеше, чыганаклары һәм күләмнәре буенча анализ үткәрелде.

Шулай ук республика бюджеты үтәлешен анализлау кысаларында Татарстан Республикасы игълан ителгән норматив йөкләмәләрен, дәүләт программаларын, программа характерындагы чараларны тормышка ашыруга үз вакытында финанслау һәм чыгымнар үтәлеше, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Резерв фонды акчаларын тоту, республиканың муниципаль берәмлекләре бюджетларына трансфертлар бирү, дәүләт бурычының торышы һәм аңа хезмәт күрсәтүгә тотылган чыгымнар мәсьәләләре каралды.

Шуннан соңгы тикшерү кысаларында хисап елында бюджет законлылыгына ярашлы рәвештә **2013 ел өчен Татарстан Республикасы бюджеты үтәлеше турында Хисап** һәм **Мәҗбүри медицина иминиятләштерүе территориаль фонды бюджеты үтәлеше турында Хисапка** тышкы тикшерү уздырылды.

Республика бюджеты үтәлеше турындагы мәгълүматларның дөреслеген һәм тулылыгын бәяләү өчен барлык төп республика бюджеты акчалары белән җитәкчелек итүчеләрнең хисабы тикшерелде.

2013 ел өчен республика бюджеты үтәлеше турынд Хисапны тышкы тикшерү нәтиҗәләре буенча бюджетның керемнәр, чыгымнар буенча үтәлеше, бюджет кытлыгын финанслау чыганакларыннан чаралар җәлеп итү расланды. Еллык хисапта республика бюджеты үтәлеше турында дөрес яки тулы булмаган фактлар ачыкланмады.

Тышкы тикшерү 2013 ел өчен бюджет үтәлеше турындагы Хисап күрсәткечләренең закон белән расланган билгеләнүләрдән тайпылышлары объектив характерда икәнлеген күрсәтте. Чыгымнарның аерым төрләре буенча бюджет акчаларын артык тотуга нигез һәм сәбәпләр бюджет законнары билгеләгән исемлеккә туры килә.

Мәҗбүри медицина иминиятләштерүе территориаль фонды бюджеты үтәлеше турында Хисапны тышкы тикшерү нәтиҗәләре буенча керемнәр, чыгымнар буенча бюджет үтәлеше расланды. Фондның тикшерүгә тәкъдим ителгән 2013 ел өчен бюджет хисаплыгы формалары күрсәткечләре һәм һәр форма буенча тикшерү нисбәтләре сакланылган. 2013 ел өчен Татарстан Республикасы Мәҗбүри медицина иминиятләштерүе территориаль фонды бюджеты үтәлеше турында еллык хисапта фактларның тулы булмаган һәм дөрес түгел чагылыш табуы ачыкланмаган.

Хисап елында камераль рәвештә **2013 ел өчен республиканың 14 югары дотацияле муниципаль районының** (Әгерҗе, Арча, Апас, Буа, Зәй, Лаеш, Менделеев, Минзәлә, Мөслим, Яңа Чишмә, Балык Бистәсе, Саба, Спас, Чирмешән) **бюджет үтәлеше турында еллык хисаплары** тикшерелде. Тикшерү нәтиҗәләре буенча түбәндәге типик бозулар һәм кимчелекләр ачыкланды:

- аерым төп администраторлар тарафыннан аларга беркетелгән идарә ителергә тиешле керемнәр буенча хисап формалаштыру буенча вәкаләтләре үтәлмәгән;

- еллык хисапка аңлатма кәгазьләре билгеләнгән таләпләргә туры килми, бу аларның мәгълүматлылыгын киметүгә китерә;

- алдагы финанс елы түләүләре исәбенә чыгымнар (артык түләүләр) барлыкка килгән;

- аерым районның бюджет чараларын төп бүлүчеләрнең җыелма еллык бюджет хисаплылыгын төзү буенча функцияләре тулы күләмдә үтәлмәгән.

Кайбер муниципаль районнарның бюджет үтәлеше турында карарларында күрсәткечләр керемнәр, чыгымнар, бюджет кытлыгын финанслау чыганаклары буенча классификация кодлары киселешендә аерым кушымталарда расланмаган, бу бюджет законы нормаларына туры килми.

Бәяләмәләр муниципаль район башлыкларына җибәрелде.

«Россия Федерациясе субъектлары һәм муниципаль берәмлекләр тикшерү-хисап органнары оештыру һәм эшчәнлегенең гомуми принциплары турында» федераль законын үтәү кысаларында 2014 елда тикшерү һәм экспертиза-аналитика чаралары үткәрү өчен **«Дәүләт (муниципаль) ихтыяҗларын тәэмин итү өчен товарлар, эш һәм хезмәт күрсәтү өлкәсендә аудит үткәрү»** тышкы дәүләт финанс тикшерүе стандарты эшләнде, **«Тикшерү чаралары үткәрүнең гомуми»** һәм **«Экспертиза-аналитика чараларын үткәрү»** тышкы дәүләт финанс тикшерүе стандартлары актуальләштерелде.

Тикшерү-ревизия эшчәнлеге

2014 елда Хисап палатасы **54** тикшерү-ревизия чарасы үткәрде, **491** объект тикшерелде. Тикшерелгән чаралар күләме **103,5** млрд сум тәшкил итте.

7 министрлыкта, 11 муниципаль берәмлектә Татарстан Республикасы бюджет чараларын куллануны тикшерү уздырылды.

Татарстан Республикасы Президенты йөкләмәсе буенча бала һәм яшүсмер спортчыларны әзерләүне тормышка ашыра торган учреждениеләргә бүлеп бирелгән бюджет чараларын куллануны тикшерү үткәрелде.

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы йөкләмәсе буенча:

- һәркемнең көченнән килерлек һәм бушлай мәктәпкәчә белем алуга хокукны тормышка ашыруга, шул исәптән баланы тәрбияләү һәм карау өчен ата-аналар түләвенең бер өлешенә компенсациягә;

- республика шәһәр һәм районнарында яшәү урыны буенча физик тәрбия һәм спорт белән шөгыльләнү өчен спорт мәйданчыклары төзүгә бүлеп бирелгән бюджет акчаларын куллануны тикшерү үткәрелде.

Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Икътисад, инвестицияләр һәм эшмәкәрлек буенча Комитеты тәкъдиме буенча 2010-2012 елларда үткәрелгән энергетика ресурсларын кулланганда бюджет чараларын тотуның нәтиҗәлелегенә аудит нәтиҗәләре буенча Татарстан Республикасы Хезмәт, мәшгульлек һәм социаль яклау министрлыгы, Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы, Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы тарафыннан күрелгән чараларның тулылыгы һәм үз вакытында булуын тикшерү үткәрелде.

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутаты Х.Г. Миргалимов мөрәҗәгате буенча Казан шәһәренең Академик Завойский урамындагы күпфатирлы торак йортлар төзелешен тәмамлауга бүлеп бирелгән бюджет акчаларын куллануны тикшерү үткәрелде.

Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре һәм спорт министрлыгының

энергетик ресурсларны кулланганда бюджет чараларын тотуның нәтиҗәлелегенә аудит үткәрелде, ачыкланган бозуларның күләме 17 936,7 мең сум тәшкил итте. Аудит нәтиҗәләре элегрәк Хисап палатасы Татарстан Республикасы Хезмәт, мәшгульлек һәм социаль яклау министрлыгы, Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы, Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгында үткәргән шундый ук аудитлар вакытында ачыкланган тискәре тенденцияләрнең Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре һәм спорт буенча министрлыгы эшчәнлегенә дә характерлы булуын күрсәтте, аерым алганда:

- ведомствога караган учреждениеләрдә энергия ресурсларын куллануның расланган нормативларын сакламау;

- ведомствога караган учреждениеләрне энергия ресурсларын исәпкә алу приборлары белән тулысынча тәэмин итүнең булмавы;

- кулланылган ресурслар өчен исәпләүләр вакытында исәпкә алу приборлары күрсәткечләрен кулланмау, шул исәптән аларның төзек булмавы яисә аларга керү юллары булмау сәбәпле;

- учреждениеләрне энергетика юнәлешендәге тикшерүләр белән тулысынча колачламау.

«Татарстан Республикасында 2010-2015 елларга һәм 2020 елга кадәр перспективада энергия саклау һәм энергетика нәтиҗәлелеген үстерү» озак вакытка исәпләнгән максатчан программасын тормышка ашыру планында каралган 34 чараның 2014 ел башына Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре һәм спорт министрлыгы тарафыннан 19 ы гына үтәлгән.

Энергия куллануның нәтиҗәлелеген күтәрүдә нәтиҗәле инструмент буларак энергия сервисы контрактлары төзү практикасы кертелмәгән.

Министрлык компетенциясендәге тармак учреждениеләре кулланган энергия ресурсларының җитештерүдән тыш чыгымнары 2009-2012 елларда 6 200 мең сум тәшкил иткән.

Татарстан Республикасы Хисап палатасы үткәргән аудит нәтиҗәләре буенча Министрлыкта энергия саклау һәм энергия нәтиҗәлелеген үстерү буенча чараларны тормышка ашыру буенча киңәшмә уздырылды, анда, ведомство карамагындагы учреждениеләргә энергия ресурсларын куллануны өч процентка киметүне исәпкә алып, бюджетларны формалаштыру буенча күрсәтмәләр бирелде.

Энергия саклау өлкәсендә үткәрелгән тикшерү чаралары буенча хисаплар Татарстан Республикасы Дәүләт Советына һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына җибәрелде.

Карбышев урамында лифт

Татарстан Республикасының “2011-2015 елларга **«Уңайлы мохит»”** озак вакытка исәпләнгән максатчан программасын тормышка ашыруга бүлеп бирелгән бюджет акчаларын куллануны тикшерү гомуми күләме 144 325 мең сум булган бозулар һәм кимчелекләр ачыкланды.

Тикшерү нәтиҗәләре буенча бозуларның 91% ы бетерелде, шул исәптән бюджетка гомуми күләме 65 963,1 мең сум булган акча кире кайтарылды.

Тикшерү тулы күләмдә эшләми торган 7 урам аркылы чыга торган җир асты һәм җир өсте юлын яраклаштырырга бүлеп бирелгән 51 293,3 мең сум күләмендәге бюджет акчасын нәтиҗәсез файдалану фактларын ачыклады: 11 лифт (14 лифттан) эксплуатацияләргә яраксыз хәлдә була, 22 данә видеокамера югалган.

Моннан тыш, Карбышев һәм Комаров урамнары буенча урам аркылы чыгу юлларыннан сүтеп алынган 2 714 мең сумлык авыш күтәрү платформалары тикшерү вакытында чит оешмада табылды. Подряд оешмаларының платформаларны урнаштыру буенча йөкләмәләре 2014 елның 30 ноябренә кадәр үтәлмәде.

К.Тинчурин исемендәге Татар дәүләт театрында, Мөмкинлекләре чикләнгән балалар һәм яшүсмерләр өчен тернәкләндерү үзәгендә (Казан шәһәре), 80 номерлы гомуми урта белем бирү мәктәбендә 4 581 мең сумга сатып алынган махсуслаштырылган җиһазлар (лифтлар, инвалид креслолары) бер елдан артык куелмыйча торды.

«Мир» кинотеатрында 3D форматында фильмнар күрсәтү өчен фактта кулланыла торган җиһаз Программа чаралары исәбенә 3 469 мең сумга сатып алынды.

Инвалидлар ихтыяҗына учреждениеләрне җайлау буенча программа чараларына карамаган эшләргә түләү фактлары ачыкланды.

Мәсәлән, Республика клиника хастаханәсендә биналарга агымдагы ремонт буенча эшләр уздырылган, Идел буе районы социаль яклау бүлегендә җылылык челтәрен төзәтү буенча эшләр башкарылган, Республика балалар клиник хастаханәсендә территорияне төзекләндерү эшләре үткәрелгән. Эшләрнең гомуми суммасы 5 337 мең сум тәшкил итә.

Торак йортның пандусы
Декабристов ур., 131

Аерым очракларда эшләр ГОСТ һәм СНиП куйган таләпләргә туры килми. Мәсәлән, торак йортларда коляскалы инвалидлар өчен пандусның факттагы авышлыгы 12% тан артып китә, култыксалар юк һәм башкалар. Шулай итеп, объектлар яраклаштыру буенча

эшләр башкарганнан соң да инвалидлар мөстәкыйль куллана алмый торган булып кала. Куелган таләпләргә туры килмәү 2014 елда эшләрне башкарганда да үз урынын таба.

Мөмкинлекләре чикләнгән балалар һәм яшүсмерләр өчен тернәкләндерү үзәгендә (Казан шәһәре), Идел буе районы социаль яклау бүлегендә, Сукырлар өчен республика махсус китапханәсендә, Республика клиника хастаханәсендә гомуми күләме 256,6 мең сум булган төзү эшләренең күләмен башкарылганнан арттырып күрсәтү ачыкланган.

Тикшерү нәтиҗәләре буенча подряд оешмалары башкарган эш күләмнәренә төзәтмәләр кертелде.

Тикшерү нәтиҗәләре 2015 елның 19 гыйнварендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетында «Уңайлы мохит» Республика программасын тормышка ашыру мәсьәләләре буенча киңәшмәдә каралды. Татарстан Республикасы Хезмәт, мәшгульлек һәм социаль яклау министрлыгына, Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгына, Татарстан Республикасы Мәдәния министрлыгына җитешсезлекләрне бетерү буенча чаралар күрү өчен 2015 елның 28 гыйнварендә кул куелган ИХ-12-11 номерлы киңәшмә беркетмәсе буенча күрсәтмәләр бирелде. Муниципаль район башлыкларына торак фондны яраклаштыру буенча эшләр башкару турында тәкъдимнәр юлланды.

Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгында үткәрелгән гомуми белем бирү учреждениеләренә **җиһазлар сатып алуга** бүлеп бирелгән бюджет чараларын куллануны тикшерү нәтиҗәләре буенча ачыкланган бозулар 18 100,9 мең сум тәшкил итте. Тикшерү чарасы вакытында сыйфатсыз җиһазлар китерү фактлары ачыкланган, куелган продукциянең ассортименты килешү шартларына туры килмәгән, монтажлау һәм эшләп карату-көйләп җибәрү буенча эшләр башкарылмаган.

Сайлап тикшерү барышында Яшел Үзән муниципаль районының 5 гомуми белем бирү мәктәбендә түбән сыйфатлы җиһазлар кайтару фактлары

ачыкланды. Алынган 27 моноблокның 12 сендә төрле кимчелек булган. Төзек булмаган җиһазларның гомуми бәясе 172 мең сум тәшкил итте.

Яшел Үзән муниципаль районының Ачасыр урта мәктәбенә кайтарылган 6 моноблокның 4-е төзек булмау сәбәпле уку процессында кулланылмаган.

Ачыкланган бозуларның күбесе дәүләт контрактларын төзегәндә сатып алу бәяләренең базар бәяләреннән шактый артык булуы белән бәйле. Мәсәлән, гомуми белем бирү мәктәпләре өчен кайтарылган химик саклану җиһазлары комплектларының бәясе бер берәмлек өчен 15,7 мең сум тәшкил итте. Шул вакытта аның базар бәясе 4,5 меңнән 5 мең сумга кадәр тәшкил итте. Нәтиҗәдә Мәгариф һәм фән министрлыгы 1 440,9 мең сум акчаны нәтиҗәсез тотты.

Гомуми күләме 344 994,6 мең сумга төзелгән 9 дәүләт контракты буенча аны үтәүчеләр товар кайтару вакытларын, аерым очракларда 4 айдан артыкка, бозганнар. Бу очракта Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы тарафыннан штраф санкцияләре түләтү буенча чаралар күрелмәгән.

Тикшерү нәтиҗәләре буенча Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгына ачыкланган бозу һәм кимчелекләрне бетерү буенча чаралар күрү өчен Күрсәтмә җибәрелде. Тикшерү чаралары материаллары Монополиягә каршы көрәш федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсенә җибәрелде.

Министрлык тәэмин итеп торучылардан 3 101 сум күләмендә штраф санкцияләре алу турында Татарстан Республикасы Арбитраж судына 3 дәгъва гаризасы җибәрде.

Министрлык Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре башкарма комитетлары җитәкчеләре исеменә алынган җиһазны нәтиҗәсез куллануга юл куймау турында хатлар җибәрде.

Татарстан Республикасы гомуми белем бирү учреждениеләрендә укучыларны **бушлай уку әдәбияты** белән тәэмин итүгә республика бюджетыннан бүлеп бирелгән чараларны куллануны тикшерү вакытында муниципаль берәмлекләрдә төрле дәреслекләргә ихтыяҗны ачыклаганда гариза формалаштыру һәм үтәүгә формаль якын килгәнлекләре ачыкланды. 14 муниципаль берәмлектә гаризалар яртысыннан да азракка үтәлгән.

Килеп туган хәлнең төп сәбәбе күп кенә мәгариф белән идарә итүче муниципаль органнарда чынбарлыкта гариза ихтыяҗын формалаштыру өчен кирәк булган район мәктәпләрен дәреслекләр белән тәэмин итү турында оператив мәгълүматлары булмауда.

Уку әдәбиятына заказ апрель аенда мәктәпләрдә алынмаган дәреслекләр санын һәм аларны яңадан бүлеп бирү мөмкинлекләрен исәпкә алмыйча формалаштырыла, ә бу соңрак шактый зур күләмнәрдә башкарыла. Мәсәлән, Казан шәһәренең 127 нче номерлы мәктәбеннән республиканың 25 мәктәбенә1388 дәреслек җибәрелгән, 12 мәктәптән 470 дәреслек алынган.

Кайбер очракларда укытучының үз инициативасы белән бер программадан икенчесенә системасыз күчүе дә урын таба.

Моңардан тыш, мәктәпләрнең дәреслекләргә ихтыяҗын формалаштырганда соңгы елларда 9 сыйныфны тәмамлаган укучылар санының сизелерлек кимү тенденциясе дә исәпкә алынмады. Нәтиҗәдә, гомуми белем бирү мәктәпләрендә 10-11 сыйныфларда укыту өчен алынмаган дәреслекләр күп санда тупланган.

Муниципаль районнарда дәреслекләргә гаризаи ихтыяҗ эксплуатация торышы яраклы хәлдә, әмма 5 елдан артык кулануда булган дәреслекләрнең куллану мөмкинлекләрен исәпкә алмыйча формалаштырыла.

Мәсәлән, 1-4 класслар өчен Технология буенча дәреслекләргә ихтыяҗ 8 543 данә булса, республика мәктәпләренә гомуми бәясе 3,5 млн сум булган алда күрсәтелгән 16 557 данә дәреслек җибәрелгән. Республика мәктәпләренә тапшырылган һәм алда кулланылмый торган дәреслекләр алуга Министрлык нәтиҗәсез тоткан акчаларның гомуми суммасы тикшерелгән вакыт аралыгында 4,5 млн сум тәшкил итте.

Үткәрелгән тикшерү нәтиҗәләре буенча Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгына чаралар күрү һәм бозуларны бетерү өчен Күрсәтмә җибәрелде.

«Җир асты транспорт корылмалары төзү буенча дирекция» дәүләт казна учреждениесенә 2012-2013 елларда **метрополитен төзүгә** бүлеп бирелгән Татарстан Республикасы бюджет акчаларын максатчан һәм нәтиҗәле куллануны тикшерү нәтиҗәләре буенча ачыклангган бозуларның күләме 411 759,2 мең сум тәшкил итте, шуларның 321 680,9 мең сумы, ягъни 78 %ы, милекне куллану белән бәйле.

Тикшерү барышында гомуми күләме 322 996,7мең сум булган бозулар юкка чыгарылды.

Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәти мөнәсәбәтләр министрлыгының 2013 елның 13 ноябрендә кул куелган 3428-р номерлы күрсәтмәсе буенча гомуми бәясе 298755,6 мең сум булган оператив идарәдән алынырга һәм муниципаль милеккә тапшырылырга тиешле дәүләт милке (метрополитен станцияләре районында җир асты туктап тору урыннары) тикшерү моментына Җир асты транспорт корылмалары төзү буенча дирекция балансында санала иде.

Шул ук вакытта «Горки» станциясендә 200 машинага исәпләнгән автомобиль кую урыны, милекче белән килешмичә, шәхси эшмәкәр тарафыннан җиңел автомобильләр өчен түләүле парковка буларак кулланылган.

88 762,5 мең сумлык бюджет акчаларын куллануның нәтиҗәлелеге һәм файдалылыгы тәэмин ителмәгән: 2010 елдан башлап бюджет акчалары озак вакытка «Челтәр компаниясе» ҖЧҖ нең дебитор бурычлылыгына тартылган.

Дирекция 2010 елның октябрендә «Челтәр компаниясе» ҖЧҖ белән «Яшьлек» һәм «Төньяк вокзал» станцияләрен электр белән тәэмин итү өчен энергетика җайланмаларын технологик тоташтыру буенча хезмәтләр күрсәтүгә контрактлар төзегән. Эшләрне үтәү вакыты – 2012 елның 25 октябре. Түләү тулы күләмдә башкарылган. Тикшерү моментына (2014 елның апреле) контрактлар үтәлмәгән.

Тикшерү чаралары нәтиҗәләре буенча милек Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәти мөнәсәбәтләр министрлыгына тапшырылды, дебитор бурыч тулы күләмдә капланды.

Ачыкланган бозулар буенча мәгълүмат Россиянең Татарстан Республикасы буенча Тикшерү комитетына тапшырылды.

Татарстан Республикасы Дәүләт төзелеш күзәтчелеге инспекциясенә бүлеп бирелгән чараларны куллануны, керем

администраторы функцияләрен башкаруны тикшерү үткәрелде. Ачыкланган бозуларның гомуми күләме 126 469,6 мең сум тәшкил итә.

Милектән нәтиҗәсез куллану очраклары ачыкланды. Мәсәлән, бәясе 721 мең сум торган күчмә юл лабороториясе 2012 елда – 45, 2013 елда 34 көн генә кулланышта булган.

Инспекция шәһәр округлары һәм муниципаль районнар бюджетларына төзелеш өлкәсендәге законнарны бозудан килеп чыккан зыянны каплау өчен акчалата җәза (штраф) һәм башка төрле түләүләрдән килгән акчалата керемнәрнең администраторы булып тора.

Инспекция тарафыннан административ җаваплылыкка тарту буенча 2012 елда – 66 389,0 мең сумлык 2 430, 2013 елда – 63 713,5 мең сумлык 1 998 карар чыгарылган.

2012 елда чыгарылган карарлар буенча бюджетка – 54 227,8 мең сум, 2013 елда 52 708,0 мең сум акча кире кайтарылган. Шуның белән бергә хисапта идарә ителә торган керемнәрне исәпләү һәм китерү буенча операцияләр 2014 елдан гына чагылдырылган.

Дәүләт ихтыяҗы өчен заказ урнаштыруга бәйле бозулар ачыкланды. Тиешле чаралар үткәреп тормыйча гына 2012 елда – 6 697,0 мең сумлык 243, 2013 елда 5 799,0 мең сумлык 207 килешү төзелгән. Россия Федерациясе Бюджет кодексының 73 маддәсен бозып, дәүләт контрактлары төзүдән башка тормышка ашырылган сатып алулар реестрында сатып алына торган товарлар атамасы, китерүчеләрнең тору урыны, сатып алу вакыты турында мәгълүмат юк.

Тикшерү чарасы нәтиҗәләре буенча Дәүләт төзелеш күзәтчелеге инспекциясенә Татарстан Республикасы Хисап палатасының Күрсәтмәсе юлланды.

Тикшерү нәтиҗәләре буенча гомуми күләме 124 335,5 мең сумлык идарә ителә торган керемнәр хисапта чагылдырылды. Җибәргән бозулар өчен Инспекциянең финанс-икътисад тикшерүе бүлеге башлыгы вазыйфасыннан азат ителде.

Этил спирты, алкоголь продукциясен җитештерүне, аның әйләнеше һәм сыйфатын тикшерү һәм кулланучылар хокукын яклауны тәэмин итү буенча Татарстан Республикасы Дәүләт инспекциясендә

үткәрелгән тикшерүләр нәтиҗәсе буларак 9 162,5 мең сумлык бозулар ачыкланды.

Инспекция эшчәнлегендәге төп бозу һәм җитешсезлекләр дәүләт милкен куллану белән бәйле.

Шулай, оператив идарә итү өчен Инспекция артыннан беркетелгән гомуми бәясе 5 823,5 мең сумлык кеше тормый торган 17 бина мәҗбүри дәүләт теркәлүенә ия булмаган. Шул ук вакытта әлеге күчемсез милек бухгалтерлык исәбе буенча төп чаралар рәтендә саналган.

2 032,2 мең сумлык бюджет чараларын нәтиҗәле куллану тәэмин ителмәгән, шул исәптән чынлыкта күрсәтелмәгән коммуналь хезмәтләр (җылылык, электр энергиясе, су белән тәэмин итү) өчен 1 795,8 мең сум күләмендә түләү башкарылган.

Шулай, шәхси затныкы булган 664,2 кв. метрлы бинаны җылылык белән тәэмин итү өчен, шулай ук 134,3 кв. метр мәйданда урнашкан Кулланучылар базарына бәйсез экспертиза һәм мониторинг республика үзәгенең коммуналь хезмәтләре өчен түләүләр Инспекция тарафыннан түләнгән. Шул ук вакытта учреждениегә коммуналь хезмәтләр күрсәтү өчен түләүгә чаралар бюджеттан бүлеп бирелгән.

Тикшерү нәтиҗәләре буенча 2014 ел өчен дәүләт хезмәтләре күрсәтүгә дәүләт бурычын башкаруны финанс яктан тәэмин итүгә субсидияләр бүлеп бирү тәртибе һәм шартлары турындагы килешүгә ведомствога караган учреждениене тотуга чыгымнарны финанслауны кыскарту өлешендә 116,2 мең сумлык үзгәреш кертелде.

Кеше тормый торган биналар буенча Инспекция тарафыннан чаралар күрелгән: техник планнар төзелгән, кадастр паспортлары, документлар дәүләт теркәлүе узар өчен Росреестрга юлланды. Моннан тыш, Әгерҗе, Мамадыш, Минзәлә һәм Нурлатта урнашкан биналарга карата Дәүләт алкоголь инспекциясенең оператив идарә хокукын туктату турында карар кабул ителде.

Татарстан Республикасының хайваннар дөньясы объектларын саклау буенча Идарәне тикшерү нәтиҗәләре буенча гомуми күләме 12 159,9 мең сум күләмендә бозулар ачыкланды.

2012-2013 еллар һәм 2014 елның 4 ае вакыт аралыгында хайваннар дөньясы объектларын саклау һәм куллану өлкәсендәге дәүләт күзәтчелеген тормышка ашыру кысаларында административ җаваплылыкка тарту буенча 797 карар чыгарылган һәм зыянны каплау буенча 70 тән артык таләп куелган.

Шул ук вакытта Бюджет керемнәре администраторы вәкаләтен тормышка ашыру тәртибе эшләнмәгән. 4 144,8 мең сумлык керемнәр беренчел документлар буенча бюджет хисабында чагылыш тапмаган. Әлеге очраклар буенча Идарәнең вазыйфаи затларын административ җаваплылыкка тарту буенча беркетмәләр төзелгән.

Дәүләт милкен куллануда бозулар һәм җитешсезлекләр ачыкланды.

Шулай, Учреждение артыннан оператив идарә итү өчен беркетелгән 4 440,2 мең сумлык торак булмаган биналар тиешле мәҗбүри дәүләт теркәве хокукына ия түгел.

Казан шәһәренең К.Тинчурин урамы, 29 йорт адресы буенча урнашкан 3 мең кв.метрдан артык мәйданлы җир кишәрлегенә дә хокук билгеләүче документлар рәсмиләштерелмәгән. Идарәгә Аксубай, Биектау, Зәй, Чирмешән муниципаль районнарында түләүсез куллану өчен алынган биналар хисап буенча чагылдырылмаган.

Банк операцияләрен тикшерү бюджет классификациясе кодлары буенча икътисадый эчтәлеккә туры килмәүче гомуми күләме 219 мең сум булган акча тоту фактларын ачыклады. Бухгалтерлык хисабын бозу белән бәйле (күчемсез милек объектлары һәм товар-матди байлыкларны исәпкә алуның булмавы) гомуми күләме 3 123,5 мең сум булган бозулар ачыкланды.

Тикшерү чаралары нәтиҗәләре буенча Идарәгә чараларны куллануның нәтиҗәлелеген арттыру һәм ачыкланган бозуларны бетерүгә юнәлтелгән чаралар күрү өчен Күрсәтмә җибәрелде.

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутаты Х.Г.Миргалимов мөрәҗәгате буенча Казан шәһәренең Академик Завойский урамындагы күпфатирлы торак йортлар төзелешен тәмамлауга бүлеп бирелгән бюджет акчаларын куллануны тикшерү үткәрелде.

Йортлар төзелешен тәмамлауны финанслау «Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Дәүләт торак фонды» коммерциячел булмаган оешмасы акчалары хисабына тормышка ашырылды.

Тикшерү барышында гомуми күләме 1 131,7 мең сум булган башкарылган эшләрнең (электр монтаж эшләре – 546,2 мең сум, янәшә территорияне яшелләндерү буенча эшләр – 257,8 мең сум, керү группаларында җылы пәрдә урнаштыру эшләре – 127,5 мең сум) күләме арттырып күрсәтү ачыкланды.

Тикшерү нәтиҗәләре буенча подрядчы арттырып күрсәтү күләмендә өстәмә эшләр башкарды.

Тикшерү нәтиҗәләре буенча Дәүләт торак фондына – күрсәтмәләр, Татарстан Республикасы Прокуратурасына – материаллар, Татарстан Республикасы Дәүләт Советына, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутаты Х.Г.Миргалимовка, алданган өлештәшләрнең инициатив төркеме әгъзаларына мәгълүмати хатлар җибәрелде.

Бала һәм яшүсмер спортчылар әзерләү өчен Татарстан Республикасы бюджет акчаларын, Казан шәһәре муниципаль берәмлеге бюджеты чараларын куллануны, финанс-хуҗалык эшчәнлегенең аерым мәсьәләләрен

тикшерү барышында гомуми күләме 18 320,2 мең сумлык бозулар ачыкланды. Спорт учреждениеләре мәйданнарын коммерциячел структураларга арендага биргән чакта аренда түләвен вакытында кертмәү һәм бәясен киметү фактлары һәм башка төр бозулар табылды.

Шулай, 2013 елның октябреннән бирле «Смена» балалар-яшүсмерләр өчен спорт мәктәбендә буфет оештыру өчен бина арендалаган «АйДи» ҖЧҖ тарафыннан 2013 елның ноябреннән бирле аренда өчен түләнмәгән, шулай итеп бурыч 100 мең сумга җиткән. Моннан тыш, әлеге оешма тарафыннан чынлыкта арендаланган мәйдан килешүдә күрсәтелгәннән ике мәртәбә күбрәк булып чыккан.

«Драйв» автомәктәбе «Смена» балалар-яшүсмерләр өчен спорт мәктәбе балансында булган «Форвард» спорткомплексындагы автомобильләр куеп тору мәйданчыгыннан шулай ук бушлай кулланган. Автомобильләр куеп тору урынын автомәктәп кулланылышына тапшыру мәсьәләсе Казан шәһәре Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре комитеты белән килештерелмәгән, аренда килешүе юк.

Казанның 4 балалар һәм яшүсмерләр спорт мәктәбенең тренер-укытучыларына яшь спортчыларга республика һәм гомумроссия дәрәҗәсендәге ярышларга баруны оештыру өчен бүлеп бирелгән гомуми күләме 1 600 мең сумлык акча аванс хисабына беркетелгән «Чирмешән АТПсы» ААҖ реквизитлары белән йөрү билетлары нигезендә исәптән чыгарылган. Ләкин автотранспорт предприятиесендә үткәрелгән каршы тикшерү чынлыкта яшь спортчыларны йөртү буенча хезмәт күрсәтелмәгәнлеге һәм тикшерелә торган вакытта балалар һәм яшүсмерләр спорт мәктәбеннән бернинди акча да килмәгәнлеген ачыклады.

Тикшерү материаллары Татарстан Президентының Коррупциягә каршы сәясәт мәсьәләләре буенча Идарәсенә җибәрелде.

Дәүләт унитар предприятиеләре, устав капиталында Татарстан Республикасының өлеше булган ачык акционер җәмгыятьләренә карата кертелгән **банкротлык процедуралары нәтиҗәлелегенә анализ** нәтиҗәләре буенча 4 912,2 мең сум күләмдә бозулар ачыкланды.

Икътисадый караштан дәүләт оешмаларына карата бәйге җитештерүе (банкротлыкның бер процедурасы) күп очракларда нәтиҗәле түгел.

Кредиторларның бетерелгән таләпләренең чагыштырмача авырлыгы 12,8% тәшкил итте.

Бәйге җитештерүе барышында оешмалар мөлкәте күп очракта бәя кыймметеннән түбәнрәк дәрәҗәдә тормышка ашырыла. Мәсәлән, «Бавлыводоканал» ААҖнең бәйге массасына 120 000 мең сумлык мөлкәт кертелде. Бәйге җитештерүе барышында әлеге мөлкәт һәм дебитор бурычлылыгын тормышка ашырудан 5 000 мең сум күләмендә акча алынды.

Бәйсез бәяләүче хисабы буенча «Торак хуҗалыкның Лениногорск җитештерү тресты» ДУП мөлкәтенең базар бәясе 24 000 мең сум тәшкил итте. Бәйге җитештерүе нәтиҗәсендә мөлкәтне сатудан бурычлының исәп-хисап ясау счетына 6 000 мең сум акча керде.

Тикшерү чарасы нәтиҗәләре буенча һәм Хисап палатасы тәкъдимнәрен исәпкә алып Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты «Дәүләт унитар предприятиеләре һәм устав капиталында Татарстан Республикасының өлеше 50 процентта артык булган ачык акционерлык җәмгыятьләре җитәкчеләренең хезмәт хакы һәм премияләре күләме буенча нигезләмәләрне раслау турында» карары проектын әзерләде. Җир һәм мөлкәти мөнәсәбәтләр министрлыгы акционерлык җәмгыятьләрнең ревизия комиссияләре эше буенча методик тәкъдимнәр эшләде.

2011-2013 елларга **Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгына** газ-мотор ягулыгында эшләүче автобуслар, трамвай, троллейбуслар һәм транспорт чаралары өчен җиһазлар сатып алуга, сатып алуны субсидияләүгә бүлеп бирелгән Татарстан Республикасы бюджеты акчаларын куллануны тикшерү гомуми күләме 137 728,0 мең сум булган бозуларны ачыкланды. «КАМАЗ» лизинг компаниясе» ААҖ тарафыннан лизинг ала торган «Закамье» йөк ташучылар ассоциациясе» коммерциячел булмаган предприятиесе»ннән тартып алынган «НефАЗ» маркалы 4 автобус кулланылмаганлыгы ачыкланды. Автомобиль күчмә составын сатып алуга субсидияләр күләме 14 640 мең сум тәшкил итте.

Тикшерү нәтиҗәләре буенча «Закамье» йөк ташучылар ассоциациясе» коммерциячел булмаган предприятиесеннән тартып алынган автобуслар Яр Чаллы шәһәре халкына транспорт хезмәте күрсәтү өчен башка йөк ташучыларга бирелде.

Моннан тыш, субсидия алучылар тарафыннан автобуслар муниципаль районнарның башкарма комитетлары белән килешү төземичә һәм килештермичә торып чит оешмаларга бирелгән, шул исәптән: Яр Чаллы шәһәрендә – «НефАЗ» маркалы 94 автобус, Бөгелмә муниципаль районында – «Волгабас» маркалы 13 һәм «НефАЗ» маркалы 1 автобус. Тикшерү барышында башкарма комитетлар тарафыннан субсидияләрне бүлү турындагы карарга төзәтмәләр кертелгән.

Тикшерү нәтиҗәләре буенча мәгълүмат Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына җибәрелде.

Татарстан Республикасының шәһәр һәм районнарында тору урыны буенча **физик тәрбия һәм спорт белән шөгыльләнү өчен универсаль спорт мәйданчыклары төзүне** тикшерү нәтиҗәләре буенча гомуми күләме 45 213,3 мең сумлык бозулар ачыкланды.

Башкарылган эшләр бәясен гомуми күләме 791,1 мең сумга арттыру очраклары билгеләнгән. Мәсәлән, Азнакай шәһәрендә (бәяне арттыру 164,6 мең сум тәшкил иткән), Чистай шәһәрендә (94,1 мең сум), Бөгелмә шәһәрендә (72,4 мең сум) футбол кыры нигезенең табигый вак таштан торырга тиешле өске һәм (яки) аскы катламы салынмаган.

Биектау тимер юл станциясе бистәсендә җирлек ясау буенча эшләр башкарылмаган, урам тренажерлары өчен ком-гравий катнашмасыннан катлам түшәлмәгән. Ә хезмәт бәясе нәтиҗәдә 59,9 мең сумга арттырып күрсәтелгән.

Спорт мәйданчыклары төзү өчен дәүләт контрактлары буенча үзләштерелмәгән чаралар калдыгы тикшерү үткәргән вакытта 21 600 мең сум тәшкил итте.

Тикшерү барышында әлеге фактлар буенча эш күләмен арттырып язуны бетерүгә актлар төзелде. Татарстан Республикасы Баш инвестиция-төзелеш идарәсе тарафыннан подрядчы оешмалар тарафыннан ачыкланган кимчелекләрне бетерү буенча эш оештырылды.

Һәркемнең көче җитәрлек һәм бушлай мәктәпкәчә белем алу хокукын тормышка ашыруга, шул исәптән баланы карау һәм күзәтү өчен ата-ана түләвенең бер өлешенә компенсацияләүгә булеп бирелгән бюджет чараларын куллануны тикшерү барышында 77 991,2 мең сумлык бозулар ачыкланды. Тикшерү барышында 63 463,8 мең сум, ягъни 81% ачыкланган бозуларны бетерү буенча чаралар күрелде.

Мәктәпкәчә балалар учреждениеләренә түбән сыйфатлы һәм куллану вакыты чыккан продуктлар китерү фактлары ачыкланды.

Аукцион нәтиҗәләре буенча Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы мәктәпкәчә балалар учреждениеләре өчен 2012 елның май аенда «Мәгарифтә мәгълүмати чишелешләр»ҖЧҖ тән бер берәмлеге 24 150

сум торган 370 «HITACHI» проекторы алган. Ә 2012 елның октябрендә министрлык шундый ук проекторны шул ук товар китерүчедән һәр берәмлеге 34 825 сумга сатып алган.

Казан шәһәренең Совет районы, Югары Ослан һәм Түбән Кама муниципаль районнар мәктәпкәчә балалар учреждениеләрендә янгын сигнализациясе системалары һәм видеокүзәтүләр учреждениеләрнең балансына куелмаган, төп чаралар һәм азкыймәтле милекнең бухгалтер исәбен алып баруда башка бозулар да ачыкланды.

Бухгалтер исәбен алып баруда тупас бозу фактлары буенча Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге мәктәпкәчә учреждениеләренең 12 вазыйфаи затына карата административ хокук бозу турында беркетмәләр төзелде.

2014 елда **Алексеевск, Аксубай, Әтнә, Баулы, Югары Ослан, Чүпрәле, Алабуга, Мамадыш, Тәтеш, Тукай һәм Ютазы муниципаль районнарында комплекслы тикшерү чаралары** үткәрелде.

Муниципаль районнарда үткәрелгән тикшерү чаралары нәтиҗәләре буенча гомуми күләме 667 826,9 мең сум булган бозулар ачыкланды:

- муниципаль милек һәм җир кишәрлекләре белән идарә итү һәм куллану вакытында бозулар– 278 511,7 мең сум;

- исәп-хисап, хисаплылык мәсьәләләрен җайлаучы «Бухгалтер исәбе турында» Федераль законын, башка норматив хокукый актларны бозулар – 171 073,0 мең сум, шул исәптән бюджет хисаплылыгын бозу, бухгалтер исәбе счетларында һәм бухгалтер исәбе регистрларында хуҗалык операцияләре булмау;

- бюджет классификациясен куллану тәртибен бозулар – 70 825,6 мең сум;

- бюджет чараларын нәтиҗәсез файдалану – 43 239,6 мең сум;

- муниципаль ихтыяҗлар өчен товарлар кую, эш, хезмәт күрсәтүгә заказлар үтәү белән бәйле бозулар – 28 520,5 мең сум;

- башкарылган төзелеш-ремонт эшләре күләме – 14 241,0 мең сум;

- бюджет чараларын нәтиҗәсез куллану – 423,3мең сум;

- башка бозулар (белем бирү учреждениеләренең энергетика ресурсларын түләүгә бюджет чараларын нормативлардан артык тотуы, бюджетны югалту. Киләсе финанс елы чыгымнарын түләү, бюджет законлылыгын башка төр бозулар) – 60 992,2 мең сум.

Җир һәм мөлкәт бәйләнешләре өлкәсендә ачыкланган бозулар башлыча аренда килешүләре буенча акчаларның кереп бетмәве, тормышка ашырылган объектлар өчен түләүләр буенча вакыты чыккан бурычлар булуы, милекне нәтиҗәсез файдалану белән бәйле.

Чүпрәле муниципаль районында үткәрелгән тикшерүләр «Лидер» җир корпорациясе» ҖЧҖнең (Апас муниципаль районы) кадастр бәясе 75 322,2 мең сум булган авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге 2 700 га мәйдандагы җир кишәрлекләрен 8 058,1 мең сумга яки кадастр бәясенннән 9 тапкыр арзанрак сатуы ачыклады.

Алабуга муниципаль районында җирле бюджетка җир өчен аренда түләве буенча 3 007,9 мең сум күләмендә акча кереп җитмәве ачыкланды. Җир өчен аренда түләвен алу белән бәйле эшләр үткәрмәү һәм дәгъваның вакыты чыгу сәбәпле, җирле бюджетка 1 225 мең сум күләмендә югалту булды.

Сатыла торган күчемсез милекне бәяләү алар урнашкан җир кишәрлекләре бәясен исәпкә алмыйча үткәрелгән, бу фактта 1 012,3 мең сумлык 18 җир кишәрлегенең өченче затлар файдасына бушлай күчүенә китергән.

Шулай ук җир участокларын максатсыз файдалану да ачыкланган. Тикшерү материаллары Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәти мөнәсәбәтләр министрлыгына һәм Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгына җибәрелгән.

Алабуга муниципаль районы Җир-мөлкәт палатасының бүлек башлыгы һәм аның урынбасары административ җаваплылыкка тартылган.

Авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җир кишәрлеген автомобильләрне ягулык белән тәэмин итү станциясе урнаштыру өчен максатсыз файдалану факты буенча «Полёт» ҖЧҖ директорын Дәүләт теркәве, кадастр һәм картография федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсе штраф формасында административ җаваплылыкка тартты. Казан шәһәренең Идел буе районы суды тарафыннан «Полёт» ҖЧҖ кә административ штраф салынды. Җир кишәрлекләрен бер категориядән икенчесенә күчерү турындагы документлар килештерү өчен Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына җибәрелде.

Ютазы муниципаль районында җир кишәрлекләре өчен 396,7 мең сум күләмендәге аренда түләве буенча бурычларны алу юнәлешендә Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре палатасы тарафыннан 3 елдан артык вакыт буена чаралар күрелмәгән.

Хокук билгели торган документлар булмау сәбәпле, муниципаль район балансында саналучы 2 788,1 мең сумлык вакуум-себерү машинасы «Урыссу төзекләндерү һәм яшелләндерү буенча предприятиесе» МУПында файдаланылган.

Аксубай районы Җир һәм мөлкәт мәнәсәбәтләре палатасы муниципаль милек реестрына «Аксубай торак-коммуналь хуҗалыгының күптармаклы җитештерү предприятиесе» ААҖ устав капиталының 25%ын тәшкил иткән гомуми күләме 8 465,5 мең сумлык гади исемле акцияләрен кертмәгән. Тикшерү нәтиҗәләре буенча акцияләр пакеты муниципаль мөлкәт реестрына кертелгән, төп чаралар бухгалтер исәбендә исәпкә алынган.

Баулы муниципаль районында калган бәясе 1 091мең сум булган муниципаль милек объектларының (чаңгы базасы, уку-җитештерү комбинаты) озак вакыт буена файдаланылмаганлыгы ачыкланды. Тикшерү чарасы нәтиҗәләре буенча Баулы муниципаль районы башлыгы адресына ачыкланган бозуларны бетерү буенча чаралар күрү өчен Күрсәтмә җибәрелде.

«Ютазы районы ҮРХ» ССДБУда тиешле квалификацияле белгечләр булмау сәбәпле, 2012 елның августыннан бирле 420 мең сумлык лапароскопик диагностика комплексы эксплуатацияләнмәгән.

Тикшерү нәтиҗәләре буенча сәламәтлек саклау учреждениесе администрациясе диагностика комплексында эшләү өчен белгеч укытуны оештырган.

Тикшерү нәтиәләре буенча Әтнә, Алабуга, Чүпрәле, Тәтеш һәм Тукай муниципаль районнары территориясендә урнашкан киң таралган файдалы казылмалар чыгару буенча санкциясез карьерлар төзү фактлары ачыкланган. Мәсәлән, Чүпрәле муниципаль районында авыл хуҗалыгы

билгеләнешендә булган җирләрдә составында циалит булган токымнар һәм ком чыгару буенча 3 санкцияләнмәгән карьер эшләп килгән.

Тәтеш муниципаль районында «ФОН» ЯАҖ авыл хуҗалыгы билгеләнешендә булган җир кишәрлегендә балчык чыгару буенча карьер эшләтеп җибәргән.

Тикшерү материаллары Татарстан Республикасының Экология һәм табигый ресурслар министрлыгына җибәрелде.

Алабуга районында Кама елгасы тугаенда авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җир кишәрлегендә гомуми таралган файдалы казылмаларны законсыз табу факты буенча Дәүләт теркәве, кадастр һәм картография федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсе «Дин-Трейд» ҖЧҖ предприятиесен административ җаваплылыкка тартты.

Тәтеш муниципаль районы прокуратурасы «Фон» ЯАҖ генераль директорына карата административ хокук бозу турында эш ачты. «Карьер» ҖЧҖ законсыз эшкәртү факты буенча 15 мең сум күләмендә штраф рәвешендә административ җаваплылыкка тартылды.

Төзелеш һәм капиталь ремонтка бүленеп бирелгән бюджет чараларын куллануны тикшерү барышында шактый бозулар ачыкланды. Тикшерү Алексеевск районында «Биләр дәүләт тарихи-археологик музей-тыюлыгы» территориясендә эшләр башкарганда гомуми күләме 2 185,1 мең сум булган бәяне арттырып язу фактларын тапты. Проект-смета документациясендә каралмаган эшләргә акча түләнгән, контракт шартларын бозып, материалларны китерү һәм бәяләрне компенсацияләүгә акча күчерелгән.

Тәтеш муниципаль районында су белән тәэмин итү урам челтәрләрен төзегәндә, биотермик чокырларны ремонтлаганда һәм Жуково авылында күпфункцияле үзәк төзелешендә эшләр бәясен арттыру 2 368,9 мең сум тәшкил иткән.

Өрем торак пунктында су белән тәэмин итү урам челтәрләрен төзү бәясе 790 мең сумга арттырылган.

Тәтеш районында биотермик чокырларга капиталь ремонт буенча эшләр бәясе 584,3 мең сумга арттырып күрсәтелгән.

Тикшерү нәтиҗәләре буенча кисәтүләр бетерелгән, өстәмә эшләр күләме башкарылган. Чүпрәле муниципаль районында тикшерү нәтиҗәләре буенча күпергә капиталь ремонт буенча башкарылмаган эшләргә 429 мең сум күләмендә түләү факты ачыкланган; Югары Ослан муниципаль районында мәгариф һәм мәдәният учреждениеләрен төзү һәм капиталь ремонт үткәрү 6 объекты буенча арттыру 890 мең сум тәшкил иткән; Ютазы муниципаль районында күпфатирлы торак йортларга капиталь ремонт объектлары буенча чынлыкта башкарылмаган күләмдәге эшләргә түләү 429 мең сум булган; Тукай муниципаль районында биотермик чокырлар, су белән тәэмин итү системалары һәм территорияне төзекләндерү төзелеше һәм ремонтының 17 объекты буенча башкарылган эшләрнең бәясен арттыру 3 452,7 мең сум тәшкил иткән; Алабуга муниципаль районында башкарылган эшләр күләме 284,5 мең сумга арттырылган.

Тикшерү барышында кабул ителгән эшләргә төзәтмәләр кертелгән, подрядчылар өстәмә эш күләме башкарганнар. Әллә ничә кат күпфатирлы өйләргә капиталь ремонт белән бәйле бюджет чараларын нәтиҗәсез файдалану фактлары ачыкланды. Аерым алганда, элек ремонтланган үзәкләштерелгән җылыту системасы сүтеп алынып, аның урынына торак биналарын шәхси җылыту өчен җиһаз урнаштырылган.

Мамадыш муниципаль районында шундый чыгымнар 2 700 мең сум, Тәтеш муниципаль районында 800 мең сум тәшкил итте.

Баулы муниципаль районында бюджет чаралары 5 114,1 мең сум күләмендә нәтиҗәсез файдаланылган.

Шулай итеп, 2011 елда Күпфункцияле үзәкне урнаштыру өчен бина ремонтланган. Чыгымнар күләме 4 575,7 мең сум тәшкил иткән. Бина ремонт уздырган вакыттан бирле эксплуатацияләнми.

Дәүләт һәм муниципаль хаҗәтләр өчен товарлар сатып алу, эш, хезмәт күрсәтү өлкәсендә бозулар башлыча товарларның бәясе һәм ассортименты, сыйфаты, китерү вакытларын саклау өлешендә төзелгән контрактларның шартлары үзгәрү белән бәйле.

Әтнә, Чүпрәле, Ютазы муниципаль районнарында тикшерү чараларын үткәргәндә товар номенклатурасына туры килми торган туклану продуктлары (табигый соклар урынына нектар, суытылган кош ите урынына туңдырылганын китерү һәм башкалар) китерү фактлары ачыкланган.

Ютазы муниципаль районының 9 мәктәпкәчә балалар учреждениесендә куллану вакыты чыккан чебеш ите китерү фактлары ачыкланган.

Әлеге фактлар буенча Россия кулланучылар күзәтчелегенең Татарстан Республикасы буенча идарәсе Ютазы муниципаль районының мәктәпкәчә белем бирү учреждениеләре вазыйфаи затларына карата административ хокук бозу турында 10 беркетмә төзеде, штраф салу турында карарлар чыгарылды.

Әтнә һәм Баулы муниципаль районнарында үткәрелгән тикшерү чаралары гомуми күләме 423,3 мең сум булган бюджет акчаларын максатсыз куллану фактларын ачыклады.

Шулай итеп, «Баулы шәһәренең төзекләндерү һәм яшелләндерү буенча идарәсе» муниципаль казна предприятиесе Баулы шәһәре муниципаль берәмлеге бюджетыннан шәһәрне тоту, ремонтлау һәм хезмәт күрсәтү буенча чыгымнарны каплауга бүлеп бирелгән субсидияләр хисабына 391,9 мең сум күләмендә «Шевроле Круз» автомашинасы бәясен түләгән. Тикшерү нәтиҗәләре буенча җирле бюджеттан финанслау кыскартылган.

Тулаем алганда, 2014 елда Хисап палатасы уздырган тикшерү чаралары нәтиҗәләре буенча **2 349 977,6 мең сум** күләмендә **бозулар ачыкланды,**

шуларның 1 518 467,0 мең сумы Татарстан Республикасы бюджет чаралары буенча, 821 715,2 мең сумы – муниципаль берәмлекләр бюджетларыннан.

Комплекслы һәм тематик тикшерүләр уздырганда түбәндәгеләр ачыкланды:

– дәүләти (муниципаль) милекне кулланганда һәм аның белән идарә иткәндә – 1 123 421,0 мең сум;

– исәп һәм хисаплылык мәсьәләләрен көйләүче «Бухгалтерлык исәбе турында» Федераль законын, башка төр норматив хокук актларын бозулар – 445 209,8 мең сум, шул исәптән бюджет хисаплылыгын бозып күрсәтү, бухгалтерлык исәбе счетларында һәм бухгалтер исәбе регистрларында хуҗалык операцияләре булмау;

– бюджет чараларын нәтиҗәсез файдалану– 219 168,0 мең сум;

– дәүләт һәм муниципаль хаҗәтләр өчен товарлар китерү, эшләр башкару, хезмәт күрсәтүгә заказлар урнаштыру турында законнарны бозулар – 52 815,6 мең сум;

– бюджет чараларын максатсыз файдалану – 423,3 мең сум;

– башка төр бозулар (товар китерүчеләргә ихтыяждан артык булган хезмәт күрсәтүләр өчен чаралар күчерү, башкарылган төзелеш-ремонт эшләренең күләмен арттырып күрсәтү, киләсе финанс елы чыгымнарын түләү, башка бюджет законлылыгын бозулар) – 508 939,9мең сум.

2014 елда үткәрелгән тикшерү чаралары барышында Татарстан Республикасы Хисап палатасы ачыклаган финанс бозулары төзелеше (мең сумнарда)



Тикшерүләр нәтиҗәләре буенча **2 150 982,7** мең сум акча барлык дәрәҗә бюджетларга **кире торгызылды** һәм ачыкланган бозулар буенча **чаралар күрелде**, шулардан:

- Татарстан Республикасының консолидацияләнгән бюджетына 135 894,0 мең сум күләмендә, шул исәптән максатсыз чыгымнар кире торгызылды;
- бюджет чараларын кулланганда, республика (муниципаль) милек белән файдаланганда ачыкланган кимчелекләрне һәм башка финанс бозуларын бетерү буенча 2 015 088,7 мең сум күләмендә чаралар күрелде.

Хисап палатасы үткәргән тикшерү нәтиҗәсендә ачыкланган бозулар буенча чаралар күрү өчен 36 күрсәтмә һәм 84 мәгълүмати хат җибәрелде.

Барлык тикшерү чаралары материаллары Татарстан Республикасы прокуратурасына җибәрелде.

Шәһәр һәм район прокурорлары тарафыннан башкарма хакимият органнары, оешма һәм учреждениеләр җитәкчеләре адресына 52 күрсәтмә җибәрелде.

Хисап палатасы һәм прокуратура органнары күрсәтмәләре буенча 180 вазыйфаи зат дисциплинар җаваплылыкка тартылган, шул исәптән 4 се вазыйфаларыннан азат ителгән.

Монополиягә каршы көрәш федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсе 3 вазыйфаи затны гомуми күләме 60 мең сум булган штраф формасында административ җаваплылыкка тартты.

Ачыкланган бозу фактлары буенча Хисап палатасы хезмәткәрләре тарафыннан тикшерелгән учреждениеләр җитәкчеләре һәм баш бухгалтерларына карата административ хокук бозу турында 38 беркетмә төзелгән.

Яр Чаллы шәһәре, Алексеевск, Баулы, Ютазы муниципаль районнары, Казан шәһәренең Вахитов, Мәскәү, Яңа Савин районнары мировой судьялары беркетмәләрне карау нәтиҗәләре буенча 23 вазыйфаи затны гомуми күләме 52 мең сум булган штраф формасында административ җаваплылыкка тартты.

Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгының Терлекчелектә нәсел эше Баш дәүләт идарәсендә уздырылган тикшерү нәтиҗәләре буенча, дәүләткә 85 млн. сумнан артык зыян салып, ялган документлар бирү юлы белән җир кишәрлеге һәм андагы корылмаларны законсыз теркәү факты буенча җинаять эше кузгатылды.

Тәрбияләнүчеләрнең ярышларда катнашуын түләү өчен бүлеп бирелгән 1 600 мең сумны үзләштерү факты буенча Казанның 4 Балалар һәм яшүсмерләр өчен спорт мәктәбенең тренер-укытучыларына карата да җинаять эше кузгатылды.

2014 елда үткәрелгән тикшерү-ревизия һәм экспертиза-аналитика чаралары буенча йомгаклау документлары Хисап палатасының мәгълүмати бюллетеньнәренең 37-40 нчы саннарында басылды, шулай ук Хисап палатасының интернет-сайтында http://www.sprt.ru урнаштырылды.

Россия Федерациясе Хисап палатасы, Россия Федерациясе субъектларының тикшерү-хисап органнары белән үзара хезмәттәшлек итү

Хисап чорында **Россия Федерациясе Хисап палатасы, регионнардагы тикшерү-хисап органнары, Россиянең Муниципаль тикшерү-хисап органнары берләшмәсе** белән үзара хезмәттәшлекне үстерү ныгыту буенча буенча эш алып барылды.

2014 елда региональ тикшерү-хисап органнары берләшмәсендә оештыру үзгәрешләре булды: Ассоциация бетерелде, Россия Федерациясе Хисап палатасы каршында Тикшерү-хисап органнары берләшмәсе төзелде. Татарстан Республикасы Хисап палатасы Рәисе Берләшмә Президиумы әгъзасы, Идел буе федераль округында Берләшмәнең Бүлек җитәкчесе итеп сайланды, Татарстан Республикасы Хисап палатасы аудиторы Берләшмәнең методология мәсьәләләре буенча комиссия Рәисе урынбасары булып тора.

Россия Федерациясе Хисап палатасы каршында Тикшерү-хисап органнары Берләшмәсе эшчәнлеге кысаларында Татарстан Республикасы Хисап палатасы: «Бюджет (җирле бюджет) турында законнар үтәлү барышын агымдагы тикшерүне тормышка ашыру» һәм «Финанс аудиты нәтиҗәләрен үткәрү һәм әзерләү» стандартларын әзерләде.

2014 елда Хисап палатасында Россия Федерациясе Хисап палатасы вәкилләре, Чувашстан Республикасы Тикшерү-хисап палатасы делегациясе, Рязань өлкәсе Тикшерү-хисап палатасы, Красноярск крае Хисап палатасы, Таймыр Долгано-Ненец муниципаль районы Тикшерү-хисап палатасы вәкилләре, Сыктывкар шәһәре Тикшерү-хисап палатасы белән эшче очрашулар уздырылды.

19 сентябрьдә Татарстан Республикасы Дәүләт Советында Идел буе федераль округына керә торган Россия Федерациясе субъектларының тикшерү-хисап органнары җитәкчеләренең «Россия Федерациясенең законнары үзгәрү шартларында тышкы финанс тикшерүен үстерү перспективалары һәм тормышка ашыру практикасы. Тикшерү һәм аудитның яңа вәкаләтләре һәм юнәлешләре» темасына киңәшмәсе булды.

Киңәшмә эшендә Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин, Россия Федерациясе Хисап палатасы каршындагы Тикшерү-хисап органнары Берләшмәсе Президиумы әгъзалары, Идел буе федераль округына керүче субъектларның тикшерү-хисап органнары вәкилләре, Мәскәү шәһәре Тикшерү-хисап палатасы Рәисе, Кырым Республикасы Хисап палатасы Рәисе, Чиләбе өлкәсе Тикшерү-хисап палатасы Рәисе катнашты.

Киңәшмә барышында тикшерү-хисап органнары эшчәнлеген методологик яктан тәэмин итү, бюджет чараларын куллануның нәтиҗәлелегенә аудит үткәрү, дәүләт һәм муниципаль сатып алулар өлкәсендә аудит, дәүләт программалары проектларына экспертиза, финанс бозуларын кисәтү һәм бюджет системасының югалтуларын булдырмый калу мәсьәләләре каралды.

Киңәшмәдә катнашучылар бюджет законнары үзгәрү шартларында тышкы һәм эчке финанс тикшерүе органнары эшчәнлеген хокук, методик һәм мәгълүмати яктан тәэмин итүне камилләштерүнең мөһимлеген билгеләп үттеләр. Россия Федерациясе Бюджет кодексында, аерым законнар чыгара торган актларда үзгәрешләрне һәм 44-ФЗ номерлы «Дәүләт һәм муниципаль хаҗәтләрне тәэмин итү өчен товарлар сатып алу, эш, хезмәт күрсәтү өлкәсендә контракт системасы» федераль законын кабул итүне исәпкә алып, «Россия Федерациясе субъектлары һәм муниципаль берәмлекләрнең тикшерү-хисап органнарын оештыруның һәм эшчәнлегеның төп принциплары турында» 6-ФЗ номерлы федераль законга тиешле үзгәрешләр кертү кирәклеге турында Россия Федерациясе Хисап палатасы каршындагы Тикшерү-хисап органнары Берләшмәсенең Хокук комиссиясенә мөрәҗәгать итәргә карар чыгарылды.

Татарстан Республикасы Хисап палатасы, ЕВРОРАИ әгъзасы буларак, әлеге оешма үткәрә торган чараларда катнаша. Апрель аенда Санта-Крус-де-Тенерифтеда (Испания) «Хакимиятнең муниципаль органнарында еллык финанс хисапларына аудит» темасына ЕВРОРАИның халыкара симпозиумы

булды. Татарстан Хисап палатасын Рәис урынбасары һәм тикшерү-хисап органнары советының секретаре тәкъдим итте.

2014 елда Хисап палатасы вәкилләре докладлар белән чыгыш ясадылар. Идел буе һәм Себер федераль округларында Хисап палатасының Фәнни-тикшеренү институты филиаллары, Татарстан Республикасы Президенты Аппараты Казан (Идел буе) федераль университеты базасында оештырган квалификация күтәрү программалары кысаларында семинарлар үткәрде, шулай ук Чиләбе, Пермь, Эстәрлетамак шәһәрләрендә киңәшмәләрдә катнаштылар.

Хисап елында аудитор, икътисад фәннәре кандидаты Вәлиев А.Р. Татарстан Республикасы Хисап палатасы Рәисе редакциясендә «Бюджет чыгымнарының нәтиҗәлелеген тикшерү: теория һәм практика мәсьәләләре» исемле монография бастырып чыгарды, ул Россия Федерациясе Хисап палатасына, Россия Федерациясе субъектларының тикшерү-хисап органнарына, республиканың муниципаль тикшерү-хисап палаталарына җибәрелде. Монография зур резонанс тапты, Россия регионнарындагы хезмәттәшләреннән уңай фикерләр алынды. Тәкъдим ителгән методик якын килүләр дәүләти (ммуниципаль) чараларны куллануның нәтиҗәлелегенә аудит үткәргәндә актив кулланыла.

Муниципаль берәмлекләрнең тикшерү-хисап органнары белән үзара хезмәттәшлек итү

Хисап елында Хисап палатасы муниципаль финанс тикшерүенең нәтиҗәлелеген үстерү, республиканың тикшерү-хисап органнарының үзара хезмәттәшлеген тәэмин итүгә юнәлгән эшен дәвам итте.

Муниципаль тикшерү-хисап органнарына оештыру, хокукый, методик, мәгълүмати, шул исәптән бюджет чараларын куллануның нәтиҗәлелегенә аудит оештыру һәм үткәрү буенча ярдәм күрсәтелә. Татарстан Республикасы Хисап палатасы барлык муниципаль районнар һәм шәһәр округлары тикшерү-хисап органнарына кураторлар – аудитор һәм структура подразделениеләре җитәкчеләрен беркетте.

Һәр ай саен муниципаль берәмлекләр тикшерү-хисап органнары эшчәнлегенең мониторингы ясала.

2014 елда республика муниципаль берәмлекләренең тикшерү-хисап органнары тарафыннан 589 тикшерү-ревизия чарасы уздырылган. Барлыгы 1864 объект тикшерелгән.

Тикшерү нәтиҗәләре буенча чаралар күрелгән һәм 7 934,9 млн. сум акча муниципаль берәмлекләр бюджетына кире кайтарылган.

Муниципаль тикшерү-хисап органнары җирле үзидарә органнарының муниципаль берәмлекнең бюджет чаралары хисабына чыгымнар карала торган һәм аның формалашуына һәм үтәлешенә йогынты ясый торган норматив хокук актлары проектларына финанс экспертизасы үткәрәләр. 2014 елда 2 716 экспертиза-аналитика чарасы үткәәрелгән, 2534 эксперт нәтиҗәсе ясалган.

27 июньдә Татарстан Республикасы Дәүләт Советында Татарстан Республикасы Тикшерү-хисап органнары советының утырышы узды, биредә «Дәүләт һәм муниципаль хаҗәтләрне тәэмин итү өчен товарлар сатып алу, эш һәм хезмәт күрсәтү өлкәсендә контракт системасы турында» 44-ФЗ номерлы федераль законын тормышка ашыру белән бәйле аеруча проблемалы аспектлар тикшерелде.

Утырыш барышында шулай ук бюджет чараларын куллануның нәтиҗәлелегенә аудит үткәрү, тышкы финанс тикшерүе органнарының вәкаләтләрен тормышка ашыру, Татарстан Республикасы дәүләт программалары проектларына экспертиза үткәрү мәсьәләләре каралды.

Муниципаль тикшерү-хисап органнарына эчке финанс тикшерүе һәм эчке финанс аудитын тормышка ашыру тәртибен көйләүче норматив документларны әзерләүдә ярдәм күрсәтергә, муниципаль сатып алулар өлкәсендә аудит үткәрүгә аерым игътибар итәргә, муниципаль программалар

проектларына экспертиза үткәрергә һәм аларны тормышка ашыруны тикшерергә тәкъдим ителде.

Утырышта Россия хокук саклау академиясенең гражданнар хокукы кафедрасы доценты, юридик фәннәр кандидаты Е.Ю. Ковалькова «Дәүләт һәм муниципаль хаҗәтләрне тәэмин итү өчен товарлар сатып алу, эш һәм хезмәт күрсәтү өлкәсендә контракт системасы турында» 44-ФЗ номерлы федераль законын тормышка ашыру вакытында проблемалы мәсьәләләргә тукталып, аларны аңлатып чыгыш ясады.

14 августта Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләр Советы Президиумы утырышында Хисап палатасы мөрәҗәгате буенча республиканың муниципаль берәмлекләренең тикшерү-хисап органнарында кадр мәсьәләләре турында мәгълүмат каралды. Президиум үзенең карары белән Татарстан Республикасы җирле үзидарә органнарына тикшерү-хисап органнарының кадрлар потенциалын ныгыту буенча чаралар күрергә, хезмәткәрләрнең һөнәри дәрәҗәсен күтәрү юнәлешендә чаралар эшләп чыгарырга, муниципаль тикшерү-хисап палаталары җитәкчеләре вазыйфаларын алмаштыру өчен кадрлар резервын формалаштырырга тәкъдим итте.

Май аенда Татарстан Республикасының 12 муниципаль тикшерү-хисап органы вәкилләре Пермь шәһәрендә үткән Россия Федерациясе Муниципаль тикшерү-хисап органнары Берләшмәсенең XIII конференциясендә катнашты.

Конференциядә доклад белән Россия Федерациясе шәһәрендә үткән Россия Федерациясе Муниципаль тикшерү-хисап органнары Берләшмәсе Рәисе В.С. Катренко чыгыш ясады.

Берләшмә һәм Ревизия Комиссиясенең 2013 ел өчен эше турында хисаплар расланды. Казан шәһәренең Тикшерү-хисап палатасы Рәисе И.М. Нургалиев Берләшмәнең ревизия комиссиясе Рәисе итеп сайланды.

Октябрь аенда Чиләбе һәм Снежинск шәһәрләрендә «Финанс дисциплинасын ныгыту, финанс бозуларын кисәтү һәм бюджет системасының югалтуларын булдырмау тәҗрибәсе» темасына регионара киңәшмә һәм Россия Федерациясе Муниципаль тикшерү-хисап органнары Берләшмәсе Президиумы утырышы булып узды, аларда Татарстан Республикасы Хисап палатасы аудиторы катнашты. 23 декабрьдә булып үткән Татарстан Республикасы Тикшерү-хисап органнары Советы утырышында Монополиягә каршы көрәш федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсе, Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы, Татарстан Республикасы Прокуратурасы вәкилләре катнашты.

Утырышта 2013 елның 5 апрелендә чыккан «Дәүләт һәм муниципаль хаҗәтләрне тәэмин итү өчен товарлар сатып алу, эш һәм хезмәт күрсәтү өлкәсендә контракт системасы турында» 44-ФЗ номерлы федераль законын тормышка ашыру мәсьәләләре, җирле бюджетларның үз керемнәрен арттыру, тикшерү-хисап органнарының эшчәнлеген методик яктан тәэмин итү, шулай ук тикшерү чаралары нәтиҗәләре каралды.

Муниципаль тикшерү-хисап органнары эшенең 2015 елга төп юнәлешләре итеп түбәндәгеләр билгеләнде:

- социаль әһәмияткә ия өлкәләрдә җирле бюджет чараларын куллануның нәтиҗәлелегенә аудит үткәрү, бозуларны кисәтү һәм бетерү буенча конкрет тәкъдимнәр әзерләү;
- тикшерү нәтиҗәләре буенча чаралар күрүнең тулылыгын даими тикшерүне оештыру;
- 44-ФЗ номерлы федераль законга яраклаштырып, вәкаләтләрнең тулы күләмдә үтәлеше буенча эшне активлаштыыру;

- җир ресурсларын максатчан һәм нәтиҗәле файдалануны тикшерүне оештыру.

Совет эшчәнлеге турында мәгълүмат, норматив һәм методик документлар, квалификация күтәрү курслары турында мәгълүмат Хисап палатасының (http://www.sprt.ru) һәм Татарстан Республикасы тикшерү-хисап органнарының (http://www.ksort.ru) рәсми сайтларында урнаштырылды.

Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары һәм хокук саклау органнары белән үзара хезмәттәшлек итү

2014 елда Татарстан Республикасы Хисап палатасының эшчәнлеге Татарстан Республикасында дәүләт финанс тикшерүе мәсьәләләре буенча Ведомствоара координацияләү советы кысаларында дәвам итте.

Финанс тикшерүе органнарының үзара тәэсир итешүе Тикшерү чараларының җыелма планы нигезендә тормышка ашырылды.

Финанс-бюджет өлкәсендә бозуларны кисәтү һәм профилактикалау максатында республика министрлыкларына, ведомстволарына һәм муниципаль берәмлекләренә ел саен бозуларны һәм кимчелекләрне анализлау һәм системалаштыру нәтиҗәләре буенча Бәяләмә юллана.

Февраль аенда узган Татарстан Республикасында Дәүләт финанс тикшерүе мәсьәләләре буенча Ведомствоара координацияләү советы утырышында бюджет законлылыгында кабул ителгән үзгәрешләргә бәйле тикшерү органнары эшчәнлегенең актуаль мәсьәләләре тикшерелде, 2014 елда этаплап үз көченә керә торган дәүләт контракт системасы турында Федераль законын тормышка ашыру турында фикер алышу булды.

Декабрь аенда узган Татарстан Республикасында Дәүләт финанс тикшерүе мәсьәләләре буенча Ведомствоара координацияләү советы утырышында бюджетка түләүләрнең тулысынча һәм үз вакытында керүен, руда булмаган материаллар карьерларын төзегәндә закон таләпләре үтәлешен нәтиҗәле тикшерүне тәэмин итү проблемалары каралды.

Утырыш барышында шулай ук әйдәп баручы экспертлар катнашында Татарстан Республикасы Хисап палатасы әзерләгән Дәүләт һәм муниципаль хаҗәтләр өчен товарлар сатып алу, эш һәм хезмәт күрсәтү өлкәсендә тикшерү системасын оештыру буенча методик тәкъдимнәр каралды һәм расланды. Документта әлеге өлкәдә бозу һәм кимчелекләрнең төп куркынычлары билгеләнде, тикшерү эшчәнлегенең өстенлекле мәсьәләләре вәкил органнар арасында бүленде.

Ведомствоара координацияләү советы тәкъдимнәрен искә алып, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2014 елның 2 маенда чыгарылган 331 номерлы карары белән республика дәрәҗәсендә Бюджет чараларының төп администраторлары тарафыннан эчке финанс тикшерүе һәм аудитны оештыру кагыйдәләре расланды. Совет тарафыннан шулай ук муниципаль берәмлекләргә дә методик ярдәм күрсәтелде – алар өчен җирле бюджетларга кагылышлы Эчке финанс тикшерүе һәм аудит оештыруның типлаштырылган кагыйдәләре әзерләнде һәм җиткерелде. Типлаштырылган кагыйдәләр нигезендә Россия Федерациясе Бюджет кодексына туры китереп муниципаль берәмлекләрнең башкарма комитетлары тиешле карарлар чыгарды.

Хисап палатасы хезмәткәрләре Татарстан Республикасы Президентының Коррупциягә каршы сәясәт мәсьәләләре буенча Идарәсе белән берлектә үткәрелгән коррупциягә каршы чаралар үткәрүдә гамәли ярдәм күрсәтү буенча комплекслы чараларда катнашты.

2014 елда шундый ук чаралар Яр Чаллы шәһәрендә, Арча, Зәй, Лениногорский һәм Сарман муниципаль районнарында, шулай ук Татарстан Республикасы Хезмәт, мәшгульлек һәм социаль яклау министрлыгында, «Татарстан Республикасының Баш инвестиция-төзелеш идарәсе» дәүләт казна учреждениесендә, «Казаньцентрстрой» ҖЧҖдә, Казан (Идел буе) федераль университетының Дәүләт һәм муниципаль идарәсе югары мәктәбендә, Татарстан Республикасының Төзелеш һәм экспертиза буенча дәүләт ведомстводан тыш идарәсендә уздырылды.

Һәр квартал саен Хисап палатасы, Финанс министрлыгының Казначылык департаменты, Финанс-бюджет күзәтчелеге Федераль хезмәтенең Территориаль идарәсе, Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгы ачыклаган бюджет законлылыгын бозулар буенча мәгълүматлар гомумиләштерелде.

Эшчәнлектә хәбәрдарлык

Татарстан Республикасы Хисап палатасы эшчәнлеге, Хисап палатасының Коллегия, Татарстан Республикасында дәүләт финанс тикшерүе мәсьәләләре буенча ведомствоара координацияләү Советы һәм Татарстан Республикасы тикшерү-хисап органнары Советы утырышлары һәрдаим массакүләм матбугат чараларында, шул исәптән федераль басмаларда яктыртылып торды.

Хисап палатасы эшчәнлеге турында мәгълүмат рәсми сайтта (http://www.sprt.ru), Россия Тикшерү-хисап органнары ассоциациясенең «Россия Хисап палаталары» сайтында (http://www.ach-fci.ru) һәм Россия Федерациясе Хисап палатасының Дәүләт системалы анализ фәнни-тикшеренү институтының фәнни-гамәли журналы «АКСОР хәбәрчесе»ндә («Вестник АКСОР») урнаштырылды.

«АКСОР хәбәрчесе» журналында (№3, 2014) «Татарстан Республикасы Хисап палатасына – 10 ел» күзәтү мәкаләсе, Татарстан Республикасы Хисап палатасы Рәисе А.И.Демидовның «Сатып алулар өлкәсендә аудит: үткәрү методикасы» мәкаләсе (№3, 2014) һәм Татарстан Республикасы Хисап палатасы аудиторы А.Р.Вәлиевнең «Дәүләт һәм муниципаль хезмәт күрсәтү

өчен күпфункцияле үзәкләрне булдыру һәм үстерүгә чаралар куллануның нәтиҗәлелегенә аудит: үткәрү методикасы» (№ 2, 2014) басылып чыкты.

Татарстан Республикасының рәсми сайтыннан алынган мәгълүматларны федераль мәгълүмат агентлыклары (РИА-Яңалыклар, Интерфакс-Поволжье, Прайм, ТАСС, РЕГНУМ һ.б.) файдаланды.

2014 елда Хисап палатасы сайтына 28 548 тапкыр керү теркәлгән. (2013 елда – 26 928, 2012 елда – 20 624, 2011 елда – 17 135).

Хисап палатасының вазыйфаи затлары конференцияләрдә катнашты, үткәрелгән тикшерү нәтиҗәләре буенча интервью бирделәр. Массакүләм мәгълүмат чараларында (интернет-басмалар, журналлар, газеталар һәм телевидениедә) Хисап палатасы эшчәнлеге 168 материалда һәм телесюжетта тәкъдим ителде.

Үткәрелгән тикшерү чаралары нәтиҗәләре буенча йомгаклау документлары, Хисап палатасы эшчәнлеге хроникасы квартал саен Татарстан Республикасы Хисап палатасының мәгълүмати бюллетеньнәрендә басылды. Хисап палатасы бюллетеньнәре Татарстан Республикасы Президентына, Татарстан Республикасы Дәүләт Советына, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына, Татарстан Республикасында дәүләт финанс тикшерүе мәсьәләләре буенча Ведомствоара координацияләү советы әгъзаларына юлланды.